ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 5 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында “йә дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен” сүзләрен “, дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен, тимер юлларда пассажирларга хезмәт күрсәтү өчен” сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:
а) 3 пунктта “$2^1$ өлешенең 2 пунктын,” сүзләрен төшереп калдырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:
“9) 2021 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы $2^1$ өлешенең 2 пунктын.”.

**2 статья**

Әлеге Закон 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК

Казан, Кремль
2019 ел, 14 июнь
№ 45-ТРЗ